Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ КАРАР

23.10.2024 Менделеевск ш. № 274

Түләүсез файдалануга
бина бирү турында

РФ Гражданлык кодексының 689 - 691 статьялары, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль законның 17.1 статьясы 1 пунктының 4 пунктчасы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 ел,ның 12 гыйнварендагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 31.1 статьясы нигезендә, Менделеевск шәһәренең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы тәкъдимен карап, Татарстан Республикасы муниципаль районының коммерциягә карамаган социаль юнәлешле оешмага ярдәм күрсәтү һәм муниципаль мөлкәттән нәтиҗәле файдалану максатларында,

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Россия Почтасы» акционерлык җәмгыятенә түләүсез файдалануга 10 елга түбәндәге адрес буенча урнашкан торак булмаган бина бирергә: Татарстан Республикасы, Менделеевск районы, Бәзәкә авылы, Үзәк урам (гомуми мәйданы 109,4 кв.м), кадастр номеры 16:27:070101:890.

2. Менделеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына югарыда күрсәтелгән учреждение белән муниципаль мөлкәттән түләүсез файдалану турында шартнамә төзүне тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына йөкләргә.

Совет рәисе Р.И. Беляев